# ИГЕЛЕК

Гомәров Габдулла 1909 елда Бәзәкә авылында Шәрәфетдин улы Гомәр белән Гыймазетдин кызы Хәдичә гаиләсендә туа. Габдулла туып күп тә үтми этисе вафат була. Һәм гаиләдәге 5 баланы әниләре Хәдичә үстерә. Әлбәттә, ятимлек тәмле калач түгел икәнен һәркем белә. Әмма бу гаиләдәге балалар ятимлекнең бөтен авырлыгын күңелләре аша үткәреп, үз җилкәләрендә күтәреп үсәләр. Кечкенә Габдуллага уку эләкми, бәләкәйдән үк өй тирәсендәге эшләрне караштырып, үсә төшкәч урак урып, печән чабып әнисенә булышчы булып үсә ул.

Бөек Ватан сугышы башлану белән 1941 елның 31 августында сугышка алына. Һәм шул китүдән 6 ел йөреп, сугыштан соң илне төзекләндерү эшләрендә (Копейск шәһәрен торгызуда) катнашып бары тик 1947 елда гына туган авылына әйләнеп кайта. Сугышта контужен булып өлешчә ишетү сәләтен югалта.

Кайткач авылдашы Гөлчирә белән матур гаилә коралар, 5 балага – Мәүлидә (1950), Рифкать (1951), Рәшит (1953), Рәкыйп (1957), Галиәскәргә (1960) тормыш бүләк итәләр. “Тормышта аз сүзле, гадел, тырыш эти гаиләдә балаларга карата таләпчән , кырыс иде. Кечкенәдән эшкә өйрәнеп үссеннәр, ялгыш юлга кереп китә күрмәсеннәр дип тырышкандыр инде. Рәкыйп исемле энекәшебез мәктәп тау башындагы басуда уйнаганда машинага тапталып үлгәч этиебез кисәк йомшарып калды. Икенче энебез Рәшитнең йөрәге авыру булып яшьли вафат булуы да эти-әнинең йөрәгенә мәңге төзәлмәс яра салды”, дип сөйли Мәүлидә апа.

Гомере буе колхозда төрле эшләр башкара Габдулла абый: мал-туар да карый, иген дә игә, болында печән вакытларында колхозчыларга аш та пешерә. Һәр эшне күңелен биреп җиренә җиткереп эшләгәнгәдер пешергән ашлары бик тәмле була, һәркем рәхмәт укып мактап ашый. Тырыш колхозчы буларак аның портреты озак еллар “Почет тактасы”нда тора.

Балалары, үзе теләгәнчә, хезмәт сөючән булып үсәләр. Кызы Мәүлидә апа Ижевск шәһәрендә 30 ел автозаводта хезмәт куя; Рифкать Уфа нефть-химия техникумын тәмамлап нефтебазада директор, Сургутта инженер вазифасын башкара; кече улы Галиәскәр озак еллар Түбән Каманың химия заводында аппаратчик булып эшли.

Гомер сукмагын намуслы хезмәт белән узган Габдулла абый, гомере буе күңеле белән Аллаһы Тәгаләнен барлыгы һәм берлегенә ышанып, Аллаһыдан куркып яши. Йөрәге барның теләге бар дигәндәй, пенсиягә чыгып бераз вакыты иркенәю белән янә үзенә шөгыль таба - “Олы чишмә” не карый башлый. Моны ул авылдашларыннан рәхмәт өмет итеп тә, макталу өчен дә эшләми - кешеләргә уңайлы булсын дип һәм савабы зур дип башкара. Һәрдаим төзәтеп, чистартып, җәйләрен чүп-чардан арындырып, әйләнә-тирәсендәге печәнне чабып, кышларын үзләренең капка төбеннән үк башлап кар көрәп юл ачып, боз ватып, бәке ясап тора. Игелекле эшнең иртә-киче юк - кар-буран дулыймы, кышкы чилләме, яңгыр коямы – хезмәтен бер генә көнгә дә туктатмый Габдулла абый. Бәзәкәнең иң уңган киленнәре таң белән чишмәгә суга килгәндә Олы чишмә яны инде ялт итеп тора. Яшьли кулына

корал тотып Ватаныбызның иминлеге өчен көрәшкән, кан койган , авыл халкы өчен маңгай тирен түккән ветеран Габдулла абый үзенә әйтелгән рәхмәт сүзләрен тыйнак елмаеп, уңайсызланыбрак тыңлап тора. Аның үзе өчен хезмәттән башка дөнъяның кызыгы юк, хезмәт аның өчен – яшәү мәгънәсе. Авылдашларына риясыз хезмәт иткән Г.Гомәров 2000 елның 18 мартында 91 яшендә вафат була.

Татар халкында бер мәкаль бар:
«Бер Чулпан мең таңга көзге,
Бер яхшылык мең елга өлге”, ягъни, яхшылыкны күргәзмә итеп эшләмә, яхшылыкның үзе хакына эшлә һәм, кешедән файда өмет итеп, бурычка эшләмә, яхшылык ул барыбер югалмас, үзен-үзе белдерер һәм үзеңә кайтыр.
Авылыбызның хөрмәткә лаек кешесе Гомәров Габдулла абый, аның игелекле гамәлләре турында без дә онытмасак иде, яшьләргә өлге итеп алырлык гади хезмәт кешесе белән горурланып яшәсәк иде.

*Мәкаләне Башарова Фәния Габдулла абый кызы Мәүлидә белән берлектә әзерләде. 2018 ел, июнь.*

**Гумеров Габдулла**
Дата рождения __.__.1909 Место рождения Татарская АССР, Бондюжский р-н, д. Бизяки Дата и место призыва Причина выбытия попал в плен (освобожден) Источник информации ГА Республики Татарстан
Гумаров Габдулла
Родился в с.Бизяки в 1909г.
Призван в РККА 31.08.1941г.
(Из похозяйственных книг с.Бизяки за 1940-42г.г)
Гумаров Габдулла 1909
Место рождения: с.Бизяки
Призван Бондюжским РВК 31.08.1941
(Сведения на граждан, призванных Бондюжским РВК Татарской АССР в годы Великой Отечественной войны 1941-1945 г.г.)
Многолетний смотритель Бизякинского родника «Олы чишмэ»






ОДНИК ОБУСТРОЕН
ЦЕХОМ ППН